БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 июнь 2024 ел № 252

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисан палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

(2018 елның 1 ноябрендәге 152 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 11 номерлы, 2020 елның 16 декабрендәге 35 номерлы, 2022 елның 18 гыйнварындагы 101 номерлы, 2022 елның 25 февралендәге 109 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге 144 номерлы үзгәрешләр белән)

Хезмәт өчен түләү системасы үзгәрү сәбәпле, социаль гарантияләрне тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның профессиональ эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасының 2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 15-ТРЗ номерлы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органнары аудиторларының, рәис урынбасарларының, рәисләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, депутатларның хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 182-ФЗ номерлы карарына үзгәрешләр кертү турындагы» 290 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 127 номерлы карарына (2018 елның 1 ноябрендәге 152 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 11 номерлы, 2020 елның 16 декабрендәге 35 номерлы, 2022 елның 18 гыйнварындагы 101 номерлы, 2022 елның 25 февралендәге 109 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге 144 номерлы карарлар үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында «12688» санын «13323» санына алыштырырга;

1.2. Карарның 1 нче кушымтасында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «33592» санын «35272» санына алыштырырга, «30233» санын «31745» санына алыштырырга;

1.3. Карарның 2 нче кушымтасында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «20688» санын «21723» санына алыштырырга;
- «15414» санын «16185» санына алыштырырга;

1.4. Карарның 3 нче кушымтасында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «19039» санын «19991» санына алыштырырга;
- «17390» санын «18260» санына алыштырырга.

1.5. Карарның 10 нчы кушымтасында «18 процент» сүзен «41 процент» сүзләренә алыштырырга;

1.6. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең, Контроль-хисап палатасы рәисенең, җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру Тәртибенең 8 пунктын (20 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Балтач шәһәр җирлеге башлыгын айлык акчалата бүләкләү өлешендә хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме - елга 15,24 айлык акчалата бүләкләү, хезмәт өчен түләүнең 11 төркеменә кертелгән Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары өчен елга - 14,12 айлык акчалата түләү, хезмәт өчен түләүнең 12 төркеменә кертелгән Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары өчен - елга 12,86 айлык акчалата түләү күләме, Балтач шәһәр җирлеге башлыгы урынбасарына - 14,5.»;

1.7. Карарның 20 нче кушымтасының 14 пунктындагы 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин